СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2022 г.Зеленодольск № 173

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында

2003 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- 2012 елның 15 мартындагы 135 номерлы «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»;
- 2018 елның 9 июлендәге 315 номерлы «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында Зеленодольск муниципаль районы Советының 2012 елның 15 мартындагы 135 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» ;
- 2019 елның 4 мартындагы 369 номерлы «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле

үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» Зеленодольск муниципаль районы Советының 2012 елның 15 мартындагы 135 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 9 июлендәге 315 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре белән).

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы
Советы карарына карата кушымта
2022 елның 20 маендагы
173 номерлы карары

## Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы нигезләмә

### 1 Гомуми нигезләмә

1.1. Әлеге Нигезләмә нигезендә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында (алга таба - җирле үзидарә органы) муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе һәм шартлары, шулай ук җирле үзидарә органнарында Татарстан Республикасы муниципаль хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру методикасы билгеләнә.

1.2. Конкурс муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә (алга таба – муниципаль хезмәт) дәгъва итүчеләрнең һөнәри дәрәҗәсен, аларның муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Җирле үзидарә органнарында вакантлы вазыйфаны биләүче Конкурс Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы (алга таба – район Башлыгы) йә, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы биләү конкурс нигезендә булганда, аның вазыйфаларын башкаручы зат тарафыннан игълан ителә.

1.4. Вакантлы вазыйфаны биләүгә Конкурс Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия (алга таба – Конкурс комиссиясе) тарафыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү буенча бердәм комиссия турында нигезләмәдә каралган тәртиптә (алга таба – Конкурс комиссиясе турында нигезләмә) үткәрелә.

1.5. Җирле үзидарә органнарында вакантлы вазыйфаны биләүгә Конкурс түбәндәге очракта үткәрелми:

1) сроклы хезмәт шартнамәсе төзегәндә;

2) муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең бүтән вазыйфасына билгеләгәндә, аның биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын үтәүнең медицина бәяләмәсе нигезендә башкара алмавы, ул биләгән вазыйфаны кыскарту, җирле үзидарә органы структурасын үзгәртеп кору, бетерү яки үзгәрткәндә;

3) муниципаль хезмәткә кадрлар резервына кертелгән муниципаль хезмәткәр (граждан) муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләгәндә;

4) муниципаль хезмәт вазыйфаларының әйдәп баручы, өлкән һәм кече төркеменә караган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләгәндә.

1.6..Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мобилизация бүлеге (сектор) башлыгы вазыйфасына билгеләнгәндә, аның вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне куллануга бәйлегә күрә, үткәрелми.

1.7. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә муниципаль хезмәткә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, шулай ук дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләргә аеруча туры килә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саны арасыннан сайлап алу.

1.8. Конкурслар үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

конкурс биремнәрен һәм процедураларны үтәгәндә барлык кандидатлар өчен тигез шартлар тәэмин итү;

кандидатларны һөнәри әһәмияткә ия объектив критерийлар нигезендә бәяләү;

конкурсларда катнашучылар арасыннан вакантлы вазыйфаны биләү яки кадрлар резервына кертү өчен конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезләнгән күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары таләпләренә җавап бирә торган затларны ачыклау.

1.9. Конкурсны үткәрү һәм конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында хәбәр Интернет челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Россия Федерациясе граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасының (алга таба – Федераль мәгълүмат системасы) рәсми сайтында, конкурс үткәрелгән көнгә кадәр 20 календарь көннән дә соңга калмыйча, урнаштырыла.

1.10. Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрү турында хәбәрдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы атамасы;

2) әлеге вазыйфаны биләү өчен дәгъва иүчегә карата куелган таләпләр;

3) документлар кабул итү урыны һәм вакыты;

4) әлеге Нигезләмәнең 2.4 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документлар исемлеге;

5) әлеге документлар кабул ителгән срок, шулай ук конкурс турында тулырак мәгълүмат чыганагы турында белешмәләр (телефон, факс, электрон почта);

6) конкурс үткәрү датасы һәм вакыты;

7) хезмәт шартнамәсе проекты.

1.11. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

1.12. Конкурста катнашуга кертелмәгән муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылар һәм конкурста катнашучы кандидатларның документлары аларга конкурс тәмамланганнан соң, өч ел эчендә язма гариза буенча, кире кайтарылырга мөмкин. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә бирелгән документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң алып атылырга тиеш.

1.13. Конкурста катнашу (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урыны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б.) белән бәйле чыгымнар кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## II. Конкурста катнашучылар.

2.1. Конкурста катнашуга, әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктында каралган срокта, әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктында күрсәтелгән документлар бирелгән һәм җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен кандидатларга карата таләпләргә туры килә торган гражданнар кертелә.

2.2. Граждан (муниципаль хезмәткәр) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмәү сәбәпле, шулай ук муниципаль хезмәткә керү (узу) өчен законнарда билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурста катнашырга рөхсәт ителми.

2.3. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләү өчен кандидатларга карата таләпләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән.

2.4. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы түбәндәгеләрне тапшыра:

1) әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча шәхси гариза;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосын теркәп;

3) паспорт яки аны алмаштыра торган документның күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

4) кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар;

5) хезмәт кенәгәсенең нотариаль яктан яки хезмәт итү (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе һәм (яки) эшчәнлек турында Россия Федерациясе законнары билгеләгән тәртиптә формалаштырылган белешмәләр һәм (яки) гражданның эшкә бәйле (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче мәртәбә гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш);

6) белем алу турында һәм квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук, үз ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турындагы документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

7) гражданда гражданлык хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган чирләрнең булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәп формасы);

8) 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

2.5. Муниципаль хезмәткәр, Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче (алга таба - район Советы Аппараты) һәм конкурста катнашырга теләк белдергән, әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмыйча, район Башлыгы исеменә гариза бирә.

Конкурста катнашырга теләк белдергән башка җирле үзидарә органында вазыйфа башкаручы муниципаль хезмәткәр район Башлыгы исеменә язылган гариза һәм үз куллары белән тутырылган, имзаланган һәм муниципаль хезмәт вазыйфасына үтү торган җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формадагы анкетаны тапшыра, фотосын теркәп.

2.6. Гражданның (муниципаль хезмәткәрнең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр дә граждан (муниципаль хезмәткәр) биләүгә дәгъва кыла торган муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны башкару мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Граждан биргән белешмәләрнең дөреслеген тикшерелергә тиеш.

2.7. Әлеге Нигезләмәнең 2.4 һәм 2.5 пунктларында күрсәтелгән документлар кабул итү турында мәгълүмати хәбәр Интернет челтәрендә Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырылганнан соң, 20 календарь көн эчендә Конкурс комиссиясенә шәхсән үзе, почта аша юллап яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә Федераль мәгълүмати системаны кулланып , электрон рәвештә тапшыра.

## III. Конкурсны үткәрү методикасы

3.1. Конкурсларны үткәрүгә әзерлек кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү алымларына таянуны (алга таба – бәяләү алымнары) һәм шуңа туры килә торган конкурс биремнәрен формалаштыру, ихтыяҗ

булганда, конкурс игълан итү планлаштырылган муниципаль хезмәткәрнең вакантлы вазыйфасына карата муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләре нигезләмәләрен актуальләштерүне күздә тота.

3.2. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи инструкцияләре нигезләмәләрен актуальләштерү, әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында каралган бәяләү малымнарын сайлау, аларга туры килә торган конкурс биремнәрен формалаштыру, вакантлы вазыйфаны биләп торуга конкурс игълан ителә торган, җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.3. Кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның квалификация таләпләренә туры килүен бәяләү өчен конкурс процедуралары барышында түбәндәге бәяләү алымнары кулланыла: анкета, төркем белән дискуссияләр уздыру, документ проектын әзерләү, реферат һәм башка язмача эшләр, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча практик мәсьәләләрне чишү.

3.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

3.5. Беренче этапта Конкурс комиссиясе түбәндәгеләрне оештыра:

конкурсны үткәрү турында мәгълүмат әзерләп, аны Зеленодольск муниципаль районы һәм федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтларында урнаштыра, әлеге мәгълүмат түбәндәгеләрне үз эченә ала: муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы аталышы, бу вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре, муниципаль хезмәт узу шартлары, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен (кадрлар резервына кертүгә) документлар исемлегенә туры китереп кандидатлар Конкурс комиссиясенә тапшырырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, әлеге документларны кабул итүне төгәлләү срогы, конкурсны үткәрүнең якынча датасы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, бәяләү алымнары турында белешмәләр, вазыйфаи бурычларын үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен вазыйфаи йөкләмәрен, хокукларларын һәм җаваплылыкны үз эченә алган муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкцияләре нигезләмәләре;

кандидат тарафыннан тапшырылган документларны тикшерү;

гражданның (муниципаль хезмәткәрнең) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү (һөнәри белем дәрәҗәсе, муниципаль хезмәт стажы (дәүләт граждан, дәүләт хезмәтенең башка төрләре) яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажы (тәҗрибәсе), вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре).

3.6. Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданның муниципаль хезмәткә керүенә каршы килә торган шартлар ачыкланган очракта,ул Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан язма рәвештә конкурста катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре хакында язмача хәбәр ителә. Граждан конкурста катнашу өчен документларны электрон форматта тапшырган очракта, конкурста катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре турында хәбәрнамә аңа көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелып, Федераль мәгълүмат системасын кулланып, электрон документ рәвешендә җибәрелә.

3.7. Конкурста катнашуга кертелмәгән вакантлы вазыйфаны биләүчегә дәгъва кылучы Конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

3.8. Җирле үзидарә органына муниципаль. хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидат булуы конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Вазыйфага квалификация таләпләренә туры килерлек нандидатлар булмаганда яисә бер генә кандидат булган очракта конкурс үткәрелмәгән булып игълан ителә. Бу очракта бердәндер кандидатка, кандидатлар таләп ителгән санда булмау сәбәпле, конкурсның узмаган дип танылуы хакында язма рәвештә хәбәр ителә.

3.9. Конкурсның беренче этабы төгәлләнгәннән соң, Конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабы датасы (катнашу өчен документлар кабул ителү тәмамлангач, 30 календарь көненнән дә соңармыйча), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт сере һәм закон тарафыннан сакланучы башка серне тәшкил иткән мәгълүматларга рөхсәт рәсмиләштерү очрагында конкурсның икенче этабын үткәрү вакытын район Башлыгы билгели.

Конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабы башланырга15 календарь көннән дә соңга калмыйча, район һәм Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтларында конкурсның үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турындагы мәгълүматны, конкурста катнашуга рөхсәт ителгән кандидатлар исемлеген урнаштыра һәм язма рәвештә кандидатларга, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга - көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында, Федераль мәгълүмат системасын кулланып, тиешле хәбәр җибәрә.

3.10. Конкурсның икенче этабында түбәндәге гамәлләр тормышка ашырыла:

кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын Конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү;

җирле үзидарә органында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына конкурста җиңүчене билгеләү турында Конкурс комиссиясе тарафыннан карар кабул итү;

конкурс нәтиҗәләрен район сайтында һәм Федераль мәгълүмат системасында урнаштыру.

3.11. Конкурсны үткәргәндә Конкурс комиссиясе кандидатларны белеме, муниципаль, гражданлык яки башка дәүләт хезмәтен үтәү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турында, алар тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә, шулай ук, тестлар, анкеталар, шәхси әңгәмәләр уздыру, реферат яки башка язма эшләр яздыру, документ проекты әзерләтү ысулларын үз эченә алган конкурс процедуралары нигезендә бәяли.

Район Советы аппараты тарафыннан Конкурс комиссиясе эшчәнлеге өчен, шулай ук кандидатлар конкурс процедураларын үтә алсын өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла.

3.11.1. Анкета конкурс үткәрелә торган җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан билгеләнгән сораулар буенча үтә.

Анкетага элегрәк башкарылган һөнәри эшчәнлек, һөнәри казанышлар, кандидат катнашкан чаралар (проектлар, форумнар, семинарлар һ.б.), матбугаттагы бастырылган мәкаләләре, шөгыльләре турында, шулай ук, булган рекомендацияләр яки тәкъдим хатлары турында сораулар кертелә.

Анкетага кандидатның мотивацияләрен бәяләүгә юнәлтелгән өстәмә сораулар да кертелә ала

Конкурс комиссиясе утырышы булырга 10 календарь көненнән дә соңга калмыйча кандидатларга анкета формалары юллана. Тутырылган анкетаны кандидатлар конкурс комиссиясе утырышы булырга биш көннән дә соңга калмыйча Конкурс комиссиясе секретаренә тапшыра.

Анкета сорауларына җаваплар өчен билгеләр куелмый.

Кандидатларның анкетасы шәхси әңгәмә вакытында тыңлана.

3.12.1. Реферат яки язма эш өчен (алга таба – Эш) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервына кертелү өчен конкурс үткәрелгән муниципаль хезмәт вазифалары төркеме) вазыйфаи бурычларыннан чыгып төзелгән сораулар яки биремнәр, шулау ук, күрсәтелгән вазифаларны биләүгә квалификация таләпләре кулланыла.

Конкурс комиссиясе утырышы булырга 10 календарь көненнән дә соңга калмыйча кандидатларга Эш темасы юллана, аны конкурс үткәрелә торган җирле үзидарә органы җитәкчесе билгели һәм тема Конкурс комиссиясе рәисе белән килештерелә.

Эш түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

язма эшнең күләме – ике биттән өч биткә кадәр;

шрифт – Times New Roman, үлчәме 14, берле интервал аша.

Эшне кандидатлар Конкурс комиссиясе утырышы булырга биш көннән дә соңга калмыйча Конкурс комиссиясе секретаренә тапшыра.

Эшне бәяләү нәтиҗәләре, Эш темасын билгеләгән җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан, түбәндәге критерийлар буенча чыгарылган йомгаклау баллын күрсәтеп, кыскача белешмә рәвешендә рәсмиләштерелә:

| №т/б | Критерийлар | Билге |
|---|---|---|
| 1 | Формалаштыруның билгеләнгән таләпләренә туры килә | от 0-1, биредә:<br>0-туры килми<br>1-туры килә |
| 2 | Теманың ачылышы | от 0-1, биредә:<br>0-ачылмаган<br>1 - ачылган |
| 3 | Аналитик мөмкинлекләре, фикер мантыйгы | от 0-1, биредә:<br>0-түбән дәрәҗәдә<br>1-тиешле дәрәҗәдә |
| 4 | Бирелгән тема буенча тәкъдимнәрнең нигезлелеге һәм практик куллану мөмкинлеге | 0 - 1, биредә: 0 – гамәлгә куелуы мөмкин түгел, 5 – заманча шартларда |

| | | |
|---|---|---|
| | | практик куллану дәрәҗәсе югары |
| 5 | Хокукый һәм лингвистик грамоталылык | 0 - 1, биредә:<br>0 – түбән дәрәҗәдә<br>1 - ярыйсы<br>2– югары дәрәҗәдә |

Эшне башкарган өчен кандидат 0 дән 10 баллга кадәр алырга мөмкин.

Объектив бәяләмә үткәрү максатында, кандидатлар әзерләгән Эшнең анонимлыгы тәэмин ителә.

3.12.2 Кандидатның документ проекты әзерләве аның вазыйфаи регламентларда билгеләнгән һөнәри эшчәнлегенең төре һәм өлкәсенә бәйле рәвештә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә кирәк булачак белемен һәм осталыгын практикадә бәяләү мөмкинлеге бирә

Конкурс комиссиясе утырышы булырга 10 календарь көненнән дә соңга калмыйча кандидатларга гражданин мөрәҗәгатенә җавап проекты, норматив хокукый акт проекты (аңлатма язуы проекты белән) яки муниципаль хезмәте вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларына кергән башка документ әзерләргә тәкъдим ителә. Бу максатларда кандидатларга эш башкару буенча инструкция һәм документ проектын тиешенчә әзерләү өчен кирәкле башка документлар бирелә.

Эшне кандидатлар, Конкурс комиссиясе утырышы булырга биш көннән дә соңга калмыйча, Конкурс комиссиясенә тапшыра

Биремне билгеләүне һәм алга таба әзерләнгән документ проектын алга таба бәяләүне муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелә торган җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла, Шул ук вакытта объектив бәяләмә үткәрү максатында, кандидатлар әзерләгән документ проектының анонимлыгы тәэмин ителә.

Документ проектын бәяләү нәтиҗәләре, түбәндәге критерийлар буенча чыгарылган йомгаклау баллын күрсәтеп, кыскача белешмә рәвешендә рәсмиләштерелә:

| №т/б | Критерийлар | Билге |
|---|---|---|
| 1 | Формалаштыруның билгеләнгән таләпләренә туры килә | от 0-1, биредә:<br>0-туры килә<br>1-туры килми |
| 2 | Мәсьәләнең асылын аңлау, әлеге документ проектын әзерләүгә нигез булган төп фактларны һәм проблемаларны ачыклау | от 0-1, биредә:<br>0-аңламый<br>1 – аңлый |
| 3 | Россия Федерациясе законнары нормаларын дөрес кулланып, документ проктын әзерләү өчен нигез булган проблемаларның чишелеш юлларын чагылдыру | 0 - 1, биредә:<br>0 – чишелеш тәкъдим ителмәгән,<br>5 - проблеманы хәл итүнең иң рациональ юлы тәкъдим ителгән |

| | | |
|---|---|---|
| 4 | Аналитик мөмкинлекләре, фикер мантыйгы | от 0-1, биредә:<br>0-түбән дәрәҗәдә<br>1-тиешле дәрәҗәдә |
| 5 | Хокукый һәм лингвистик грамоталылык | 0 - 1, биредә:<br>0 – түбән дәрәҗәдә<br>1 - ярыйсы<br>2 – югары дәрәҗәдә |

Әзерләнгән документ проекты өчен кандидат 0 дән 10 баллга кадәр алырга мөмкин.

3.12.3. Тестлар белән муниципаль хезмәтенә вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның Россия Федерациясенең дәүләт телен (рус телен) белүе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләрен белүе, Россия Федерациясенең муниципаль хезмәте турындагы һәм коррупциягә каршы тору буенча законнарын белүе, мәгълүмати коммуникацияләр технологиясе өлкәсендә белемнәре һәм күнекмәләре, шулай ук, һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсендә һәм төрендә белемнәре һәм күнекмәләре бәяләнә.

Тестны оештыру конкурс комиссиясе тарафыннан, әлеге Нигезләмә һәм Конкурс комиссиясе турындагы нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

Конкурс комиссиясе секретаре кыска белешмә рәвешендә нәтиҗәләрне 10 баллы системага күчереп кыска белешмә рәвешендә формалаштыра.

3.12.4. Кандидатлар белән шәхси әңгәмәләрне Конкурс комиссиясе әгъзалары үткәрә.

Шәхси әңгәмә кысаларында Конкурс комиссиясе әгъзалары кандидатның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүгә юнәлтелгән, шул исәптән тутырылган анкеталарны һәм башкарылган язма эшләрне исәпкә алып, сораулар бирәләр.

Бу максатларда муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын исәпкә алып, муниципаль хезмәтнең һәр вакантлы вазыйфасы буенча сораулар исемлеге төзелә. Сораулар исемлеге Конкурс комиссиясе утырышына җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан әзерләнә.

Кандидат белән шәхси әңгәмә тәмамлангач, Конкурс комиссиясе әгъзасы кандидатны бәяләү нәтиҗәсен әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча төзелгән конкурс бюллетенына кертә

Шәхси әңгәмә үтү нәтиҗәләре буенча кандидат 0 дән 10 баллга кадәр алырга мөмкин.

Шәхси әңгәмә нәтиҗәләре буенча кандидатның йомгаклау баллы конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кандидатка куелган уртача арифметик балл суммасы буларак билгеләнә.

3.13. Кандидатның йомгаклау баллы конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан шәхси әңгәмә, тест һәм конкурс биремен бәяләү нәтиҗәләре буенча куелган баллар суммасы буларак билгеләнә.

Кандидатларның йомгаклау балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча Конкурс комиссиясе йомгаклау баллары кимү тәртибендә кандидатлар

рейтингын формалаштыра

Иң күп балл җыйган кандидат муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңүче дип таныла.

3.14. Әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымта нигезендә Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе бланкына кертелгән Конкурс комиссиясе карары конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып тора.

3.15. Конкурс үткәрү нәтиҗәсендә муниципаль хезмәте вакант вазыйфасын биләү өчен (кадрлар резервының муниципаль хезмәте вазыйфалары) квалификацион таләпләргә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, Конкурс комиссиясе конкурста җиңүче табылмавы турында карар кабул итә

3.16. Конкурс комиссиясе муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы конкурсында җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәягә лаек булган кандидатны җирле үзидарә органнарының кадрлар резервына кертү турында тәкъдим сыйфатында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге кандидатның җыелган балларының гомуми суммасы максималь баллның 50 процентыннан да ким булмаска тиеш.

Кандидатның язмача яки көчәйтелгән квалификацияләнгән электрон имзасы куелган электрон документ форматындагы риза булу шарты белән, аны муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына карый торган шул ук төркемдәге муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү буенча кадрлар резервына кертү турында район Башлыгы боерык чыгарыла

3.18. Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрләр, конкурс тәгәлләнгәннән соң, җиде көн эчендә, конкурста катнашучыларга язмача рәвештә юллана, документларын электрон форматта тапшырган кандидатларга – Федераль мәгълүмат системасын кулланып, көчәйтелгән квалификацияләнгән электрон имза куелган электрон документ форматында.Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук күрсәтелгән вакыт эчендә  Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Федераль мәгълүмат системасында урнаштырыла.

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
җирле үзидарә органнарында
муниципаль хезмәтнең вакантлы
вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү
турындагы нигезләмәгә
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск
муниципаль районы Башлыгына

______________________________
*(районы Башлыгы инициаллары, фамилиясе)*
______________________________
*(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе*
______________________________
*иseme, атасының исеме, соңгысы– булган очрkkта)*
______________________________
*(гариза тапшырган вакытка яшәү урыны адресы,*
______________________________
*эшләү урыны,*
______________________________
*вазыйфасы)*
______________________________
*(мобиль телефон номеры,*
______________________________
*электрон почта адресы)*

гаризаа.

Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашуга рөхсәт итүегезне сорыйм:

______________________________
*(Структур бүлекчәнең һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органының*
______________________________
*муниципаль хезмәт вазыйфасы аталышы күрсәтелә)*
______________________________
______________________________
(идарәнең, бүлекнең, вазыйфасының аталышы)

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» гы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте турында башка норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә белән, шул исәптән вакантлы вазыйфага куела торган квалификация таләпләре белән таныштырылды. Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Персональ мәгълүматлар турында» гы Федераль закон таләпләре нигезендә риза.

Конкурс (тест) үткәрү датасы, урыны, тәртибе турында e-mail аша хәбәр ителүенә яисә күрсәтелгән мобиль телефонга смс-хәбәр җибәрелүгә ризалык бирәм.

Гаризага түбәндәгеләрне терким:

___________________________________________________________________________
(беркетелгән документларны санап чыгарга)

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

_______________ _______________ _______________________

(дата) (имза) (имза аңлатмасы)

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
җирле үзидарә органнарында
муниципаль хезмәтнең вакантлы
вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү
турындагы нигезләмәгә
2 нче кушымта

Конкурс бюллетене

«___» _________________ 20___ел
конкурсны үткәрү датасы
Конкурс комиссиясе утырышында Конкурс комиссиясе әгъзаларының ____________катнашты:

Комиссия рәисе: ____________________
*фамилиясе, инициаллары*

Комиссия рәисе урынбасары: ____________________
*фамилиясе, инициаллары*

Конкурс комиссия секретаре: ____________________
*фамилиясе, инициаллары*

Конкурс комиссиясе әгъзалары:
____________________
*фамилиясе, инициаллары*
____________________
*фамилиясе, инициаллары*
____________________
*фамилиясе, инициаллары*
____________________
*фамилиясе, инициаллары*
____________________
*фамилиясе, инициаллары*
____________________
*фамилиясе, инициаллары*

1. Муниципаль хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелде

________________________________________________
*(структур бүлекчәнең, вазыйфасының аталышы)*
________________________________________________

Кандидатлар белән шәхси әңгәмә нәтиҗәләре:

1. ____________________
*Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе и инициаллары*

| Кандидатның ФИАт.и. | балл ( 0 дан 10 га кадәр) |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

2. ____________________
*Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе и инициаллары*

| Кандидатның ФИАт.и. | балл ( 0 дан 10 га кадәр) |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

3. ________________________________________
*Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе и инициаллары*

| Кандидатның ФИАт.и. | балл ( 0 дан 10 га кадәр) |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

4. ________________________________________
Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе и инициаллары

| Кандидатның ФИАт.и. | балл ( 0 дан 10 га кадәр) |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

5. ________________________________________
*Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе и инициаллары*

| Кандидатның ФИАт.и. | балл ( 0 дан 10 га кадәр) |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

6. ________________________________________
*Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе и инициаллары*

| Кандидатның ФИАт.и. | балл ( 0 дан 10 га кадәр) |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

7. ________________________________________
*Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе и инициаллары*

| Кандидатның ФИАт.и. | балл ( 0 дан 10 га кадәр) |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

8. ________________________________________
*Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе и инициаллары*

| Кандидатның ФИАт.и. | балл ( 0 дан 10 га кадәр) |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

9. ________________________________________
*Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе и инициаллары*

| Кандидатның ФИАт.и. | балл ( 0 дан 10 га кадәр) |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

Шәхси әңгәмәнең йомгаклау нәтиҗәсе

| Кандидатның ФИАт.и. | уртача балл |
|---|---|

| | |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

Нәтиҗәләргә шәрехләр (кирәк булса)

Комиссия рәисе: ____________________

*фамилиясе, инициаллары*

Комиссия рәисе урынбасары: ____________________

*фамилиясе, инициаллары*

Конкурс комиссия секретаре: ____________________

*фамилиясе, инициаллары*

Конкурс комиссиясе әгъзалары: ____________________

*фамилиясе, инициаллары*

____________________

*фамилиясе, инициаллары*

____________________

*фамилиясе, инициаллары*

____________________

*фамилиясе, инициаллары*

____________________

*фамилиясе, инициаллары*

____________________

*фамилиясе, инициаллары*

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
җирле үзидарә органнарында
муниципаль хезмәтнең вакантлы
вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү
турындагы нигезләмәгә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча бердәм конкурс комиссиясе утырышы
БЕРКЕТМӘСЕ

«___» __________________ 20___ел
конкурс үткәрелү датасы

Конкурс комиссиясе утырышында ______ конкурс комиссиясе әгъзасыннан түбәндәгеләр катнашты:

Комиссия рәисе: ______________________
*фамилиясе, инициаллары*

Комиссия рәисе урынбасары: ______________________
*фамилиясе, инициаллары*

Конкурс комиссиясе секретаре ______________________
*фамилиясе, инициаллары*

Конкурс комиссиясе әгъзалары:
____________________
*фамилиясе, инициаллары*
______________________
*фамилиясе, инициаллары*
______________________
*фамилисе, инициаллары*
______________________
*Фамилиясе, инициаллары*
______________________
*фамилиясе, инициаллары*
______________________
*фамилиясе, инициаллары*

1. Муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелде
________________________________________________________________
(структур бүлекчәнең, вазыйфасының аталышы)
________________________________________________________________

Кандидатларның тест буенча нәтиҗәләре:

| Кандидатның ФИАт.и. | балл ( 0 дан 10 га кадәр) |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

Кандидатларның конкурс биреме нәтиҗәләре:

| Кандидатның ФИАт.и. | балл ( 0 дан 10 га кадәр) |
|---|---|
| | |

| | |
|---|---|
| | |

Шәхси әңгәмә нәтиҗәләре (конкурс бюллетене)

| Кандидатның ФИАт.и. | уртача балл |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

Кандидатларның рейтинг бәяләвенең йомгаклау нәтиҗәсе:

| Кандидатның ФИАт.и. | Йомгаклау баллы | Рейтингтагы урыны (кимү тәртибендә) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

Конкурс җиңүчесен билгеләү буенча тавыш бирү нәтиҗәләре (барлык кандидатлар буенча тутырыла)

______________________________________________

(кандидатның ФИАт.и.)

| Конкурс комиссиясе әгъзасының ФИАт.и. | Тавыш бирү | | |
|---|---|---|---|
| | «риза» | «каршы» | «тыелып калды» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

______________________________________________

(кандидатның ФИА.и)

| Конкурс комиссиясе әгъзасының ФИАт.и. | Тавыш бирү | | |
|---|---|---|---|
| | «риза» | «каршы» | «тыелып калды» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәләренә шәрехләр (кирәк булганда)

___

___

___

___

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Конкурс комиссиясе конкурсның җиңүчесе дип түбәндәгене таныырга

___

(кандидатның ФИАт.и.)

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Конкурс комиссиясе муниципаль хезмәтнең кадрлар резервына түбәндәге кандидатларны кертергә тәкъдим итә:

___

(кандидатның ФИАт.и.)

___

(кандидатның ФИАт.и.)

Комиссия рәисе:

___

*фамилиясе, инициаллары*

Комиссия рәисе урынбасары:

___

*фамилиясе, инициаллары*

Конкурс комиссия секретаре:

___

*фамилиясе, инициаллары*

Конкурс комиссиясе әгъзалары:

___

*фамилиясе, инициаллары*

___

*фамилиясе, инициаллары*

___

*фамилиясе, инициаллары*

___

*фамилиясе, инициаллары*

___

*фамилиясе, инициаллары*

___

*фамилиясе, инициаллары*